СОВЕТ НОРМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
НОРМА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ**

«5» июль 2018 ел

**КАРАР**

№ 89

«Җир салымы турында» 2014 елның 12 ноябрендәге 122 номерлы карарга (2015 елның 18 сентябрендәге 6 номерлы редакциясендә) үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешенә һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 30 сентябрендәге 286-ФЗ номерлы Федераль закон белән Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешенә үзгәрешләр кертү сәбәпле, «Норма авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. «Җир салымы турында» 2014 елның 12 ноябрендәге 122 номерлы карарга үзгәрешләр кертергә:

1.1. Карарның 4 пунктын түбәндәге эчтәлекле абзацлар белән тулыландырырга:

«Салым түләүчеләр - салым ташламалары хокукына, шул исәптән салымнар һәм җыемнар турындагы законнарда билгеләнгән салым тотып калуы рәвешендә, ия физик затлар салым органына үз теләге белән салым ташламасын бирү турында гариза тапшыралар, шулай ук салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслаучы документлар тапшырырга хокуклы.

Салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслау Салым Кодексының 361.1 статьясындагы 3 пунктында каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.».

2. Әлеге карар «Хезмәт» район газетасында рәсми басылып чыккан көннән бер айдан ким булмаган вакыт узгач һәм чираттагы салым чорының 1 числосыннан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә.

Рәислек итүче
Норма авыл җирлеге Советы депутаты С. М. Исрафилов